Кукмара муниципаль районы
Урта Кумор авыл җирлеге Советы

КАРАР

«20» март 2020 ел № 11

Кукмара муниципаль районы Урта Кумор авыл җирлеге муниципаль хезмәт турында Урта Кумор авыл җирлеге Советының 2018 елның 27 апрельдәге 8 номерлы карары белән расланган Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында»2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, муниципаль хезмәт турында 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Кодексы нигезендә, Урта Кумор авыл җирлеге муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәне гамәлдәге законнарга туры китерү максатыннан, Урта Кумор авыл җирлеге Советы карар бирде:

1.Кукмара муниципаль районы Урта Кумор авыл җирлеге муниципаль хезмәт турында Урта Кумор авыл җирлеге Советының 2018 елның 27 апрельдәге 8 номерлы карары белән расланган Нигезләмәгә ( Урта Кумор авыл җирлеге Советының 2018 елның 07 ноябрендәге 31 номерлы, 2019 елның 16 маендагы 11 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 9 бүлекнең 1 пунктында:

- 2 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

2) түбәндәге очраклардан тыш, коммерциячел оешма белән яисә коммерциячел булмаган оешма белән идарә итүдә катнашырга:

а) сәяси партия, һөнәр берлеге органы, шул исәптән муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә органында, сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән башлангыч һөнәр берлегенең сайланулы органы белән идарә итүдә, башка иҗтимагый оешманың, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативлары, күчемсез мөлкәт милекчеләре ширкәтләре съездында (конференциясендә) яисә гомуми җыелышында түләүсез нигездә катнашу;

б) актта билгеләнгән тәртиптә алынган яллаучы вәкиле рөхсәте белән түләүсез нигездә коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә (сәяси партия, һөнәр берлеге органы, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән башлангыч профсоюз оешмасының сайланулы органы белән идарә итүдә, башка иҗтимагый оешманың, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативларының, күчемсез милек милекчеләр ширкәтенең съездында (конференцияләрдә) яисә гомуми җыелышта катнашудан тыш) катнашу;

в) Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре советында, муниципаль берәмлекләрнең башка берләшмәләрендә, шулай ук аларның идарә органнарында түләүсез нигездә муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен кайгырту;

г) муниципаль берәмлек исеменнән оешманың гамәлгә куючысы вәкаләтләрен башкару яисә муниципаль милектә булган акцияләр (устав капиталында катнашу өлешләре) белән идарә итү тәртибен билгеләгән муниципаль хокукый актларга таянып, муниципаль берәмлек гамәлгә куючысы (акционеры, катнашучысы) булган оешманың идарә органнарында һәм ревизия комиссиясендә түләүсез нигездә муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен кайгырту;

д) федераль законнарда каралган башка очраклар;

- түбәндәге эчтәлекле 2.1 пункты белән тулыландырырга:

«2.1) шәхсән яисә ышанычлы затлар аша эшмәкәрлек эшчәнлеге белән шөгыльләнергә;»;

1.2. 10 бүлекнең 13 пунктында «башка дисциплинар җәза» сүзләрен «башка җаваплылык чаралары» сүзләренә алмаштырырга»;

1.3. 12 бүлектәге 1.3 пунктның 6 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6) индивидуаль (персонификацияләнгән) исәпкә алу системасында теркәлүне раслаучы документ, шул исәптән электрон документ рәвешендә;»

1.4. 20 бүлекнең 5 пунктындагы икенче абзацында «ә стаж озынлыгы һәм айлык түләүләр муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы Кодексы нигезендә тиешле еллар эшләгән өчен пенсия күләмен билгеләгәндә муниципаль хезмәткәргә билгеләнгән күләмдә исәпкә алына» сүзләрен «ә класслы чин өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмә түләү Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативларын билгели торган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының норматив хокукый акты белән билгеләнгән күләмдә исәпкә алына.» сүзләренә алмаштырырга;

1.5. 23 бүлекнең 3 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Дисциплинар җәзаларны куллану һәм кире алу тәртибе «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законда каралган очраклардан тыш, хезмәт турындагы законнарда билгеләнә

1.6. 24 бүлекнең 9 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

9. Әлеге Нигезләмәнең 7, 10 һәм 23 пунктларында каралган җәзалар, муниципаль хезмәткәрнең вакытлыча эшкә яраксызлыгы, отпускта булу чорларын санамыйча, муниципаль хезмәткәр тарафыннан коррупциячел хокук бозу кылу турында мәгълүмат кергән көннән алып алты айдан да соңга калмыйча һәм коррупциячел хокук бозу кылган көннән өч елдан да соңга калмыйча кулланыла. Күрсәтелгән вакытларга җинаять эше буенча производство вакыты керми.»

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм махсус мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Авыл җирлеге башлыгы
урын басары: И.С.Германова